ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 октябрь 2024ел № 6845

2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1541 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2025 елга расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны кушымтада каралганча;

2) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,75 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2024 елның 17 октябрендәге
6845 номерлы карарына
кушымта

2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү
мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (елына 1 укучыга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 78 737 | 89 952 | 115 527 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 41 684 | | 37 010 | 88 817 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 87 814 | 72 312 | 265 068 |
| Гомуми эстетика сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 36 926 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 80 741 | 77 524 | 124 555 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 121 586 | | 116 554 | | 191 128 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 62 682 | | 58 352 | 58 267 | 87 898 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Г.А. Шәфыйкова